ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 451-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 451-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2054-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында**

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә күрсәтелгән өлкәдә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) җиңел такси – гавами фрахтлау шартнамәсе нигезендә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен кулланыла торган җиңел автомобиль;

2) рөхсәт – Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә юридик затка, шәхси эшмәкәргә яки физик затка җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокук бирә торган электрон документ;

3) физик зат – «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланган һәм шәхси эшмәкәр булмаган кеше;

4) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы – Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Закон белән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат;

5) җиңел таксига заказ бирү хезмәте – фрахтовкалаучы булырга ниятләгән кешедән аның белән җиңел таксины фрахтовкалау турында ачык килешү төзү максатыннан җиңел таксига заказ алу, һәм (яки) фрахтовкалаучы булырга ниятләгән

кешегә тапшыру буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга хокук бирелгән юридик зат яки шәхси эшмәкәр.

2. Әлеге Законда кулланылучы бүтән төшенчәләр федераль законнардагы мәгънәсендә кулланыла.

3 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә керә:

1) җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба-вәкаләтле орган) билгеләү;

2) рөхсәт бирү, аны туктатып тору, юкка чыгару һәм рөхсәтне яңарту тәртибен билгеләү;

3) вәкаләтле органга гариза яки Федераль законның 4 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне һәм аларга кушып бирелә торган документларны җибәрү тәртибен билгеләү;

4) җиңел такси йөртүчеләре турында мәгълүмат составын һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан әлеге мәгълүматларны вәкаләтле органга җибәрү тәртибен билгеләү;

5) җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан вәкаләтле органга вәкаләтле орган тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләрнең һәм багаж ташучыларның төбәк реестрына һәм (яки) җиңел таксиларның төбәк реестрына кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат алуның техник мөмкинлеге булмау турында хәбәр итү тәртибен билгеләү;

6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланмыйча үз эшчәнлеген алып баручы җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр, аларның бәясе һәм мондый хезмәтләр өчен түләү кагыйдәләре турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен билгеләү;

7) җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру тәртибен һәм чыганакларын билгеләү, әгәр җиңел таксига заказ бирү хезмәте үз эшчәнлеген «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып башкаруны күздә тотмаса;

8) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы (моңа рөхсәт алу турында гариза бирергә ниятләгән кеше) физик зат (алга таба – заказчы) тарафыннан вәкаләтле органга заказчыга куллануга аның турында мәгълүматлар җиңел таксилар төбәк реестрына кертелгән җиңел такси бирү, такси бирүнең сроклары турында заказчы җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы хәбәр итүнең тәртибен билгеләү;

9) җиңел таксида пассажирлар йөртүченең һәм багаж ташучының җиңел такси заказы хезмәтенә җиңел такси йөртүчесе тарафыннан Федераль законның 19 статьясының 3 өлешендәге 8 пунктында каралган таләпләрне бозу турында мәгълүмат тапшыру тәртибен билгеләү;

10) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау;

11) Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

12) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле органның вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле органның вәкаләтләренә керә:

1) рөхсәт бирү, аны туктату, юкка чыгару һәм рөхсәтне яңадан гамәлгә кертү;

2) җиңел такси заказ хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирү, җиңел такси заказ хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын туктатып тору, гамәлдән чыгару һәм яңарту;

3) җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучыларның төбәк реестрын, җиңел таксиларның төбәк реестрын һәм җиңел таксига заказ бирү хезмәтләренең төбәк реестрын (алга таба – төбәк реестрлары) алып бару;

4) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар тарифлар турында мәгълүмат урнаштырсын өчен Федераль законның 24 статьясының 2 өлешендә күздә тотылган сайтны билгеләү;

5) Федераль законның 4 статьясының 1 өлешендә каралган гаризалар һәм белдерүләр формаларын, күрсәтелгән гаризаларга һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучыларның региональ реестрыннан, җиңел такси заказ хезмәтләренең региональ реестрыннан өземтәләргә карата карарлар кабул итү турында белдерүләрне раслау;

6) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

7) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча эшчәнлек юридик затка, шәхси эшмәкәргә яки физик затка бирелә торган һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучыларның төбәк реестрындагы язма белән

расланган рөхсәт нигезендә, рөхсәтнең гамәлдә булуы туктатылмаган яки юкка чыгарылмаган очракта, җиңел таксиларның төбәк реестрына мәгълүмат кертелгән транспорт чараларын кулланып гамәлгә ашырыла.

3. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә рөхсәт биш еллык срокка бирелә, физик затларга рөхсәт биш елга яки физик зат рөхсәт бирү турында гаризада аны күрсәткән очракта аннан да азрак срокка бирелә.

4. Җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелә торган вакыт биш ел тәшкил итә.

6 статья. **Җиңел таксига куелган таләпләр**

1. Җиңел такси Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә рәсмиләштерелергә тиеш. Җиңел такси кузовының төсләр гаммасы ак яки сары төсләр гаммасына туры килергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлешендә каралган мәгълүматны ике үлчәмле штрихлы код (QR-код) рәвешендә яки «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге күрсәтелгән мәгълүмат урнаштырылган сайт адресы турында мәгълүматны җиңел такси салонында урнаштыру мөмкинлеге билгеләнергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән җиңел такси сыйфатында кулланыла торган транспорт чарасының экологик классына өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

7 статья. **Төбәк реестрлары**

1.Төбәк реестрларын алып бару Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртиптә җиңел таксиларның федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксиларның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мәгълүматлар составы, вәкаләтле орган тарафыннан мондый мәгълүмат системасына мәгълүмат бирү тәртибе, вакыты, ысуллары җиңел таксиларның федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

8 статья. **Аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә, мондый хезмәтләрне тәкъдим итү һәм (яки) рәсмиләштерү өчен җиһазландырылган урыннардан тыш, җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтү тәкъдименә тыю, аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар

территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин.

9 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә ярашлы рәвештә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып Федераль законның 30 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора.

3. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнә.

4. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә ярашлы рәвештә даими рейд үткәрелә. Даими рейдны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

10 статья. **Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 4 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2021, № 77 (I өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган тарафыннан 2023 елның 1 сентябренә кадәр бирелгән

рөхсәт аларның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы гамәлдә, әмма күрсәтелгән көннән биш елдан артык түгел.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә эшләнде.

Закон проекты белән республика территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мәсьәләләре, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру мәсьәләләре җайга салына, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының вәкаләтләре билгеләнә.

Федераль законның 5 һәм 14 статьяларын тормышка ашыру максатларында закон проектында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирә торган рөхсәт биш елга бирелү, физик затка мондый рөхсәт биш елга яки гаризада күрсәтелгән аннан да азрак вакытка бирелү күздә тотыла. Җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен биш еллык срок билгеләү күздә тотыла.

Җиңел таксиларда пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучыларның төбәк реестрын, җиңел таксиларның төбәк реестрын һәм җиңел таксига заказ бирү хезмәтләренең төбәк реестрын алып бару Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә җиңел таксиларның федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләнә.

Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктын үстерү максатыннан җиңел такси кузовының төсләр гаммасына таләп билгеләнә (ак яки сары төсләр гаммасына туры килергә тиеш), бу җиңел таксины идентификацияләүне җиңеләйтергә ярдәм итә.

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм аңа үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләү таләп ителә:

рөхсәт бирү, аны туктатып тору, рөхсәт бирүнең гамәлдә булуын туктату һәм яңарту тәртибен;

вәкаләтле органга гаризалар яки хәбәрләр һәм аларга кушып бирелә торган документларны җибәрү тәртибен;

җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан вәкаләтле органга җиңел такси йөртүчеләре турында мәгълүмат җибәрү һәм шундый мәгълүматлар составы тәртибен;

җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан вәкаләтле органга вәкаләтле орган тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучыларның төбәк реестрына һәм (яки) җиңел таксиларның төбәк реестрына кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат алуның техник мөмкинлеге булмау турында хәбәрнамә җибәрү тәртибе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып үз эшчәнлеген алып бармый торган җиңел такси заказ хезмәте тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучылар күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр, аларның бәясе һәм мондый хезмәтләр өчен түләү кагыйдәләре турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 317 номерлы һәм «Җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 сентябрендәге 929 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2011 елның 6 декабрендәге 999 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану таләп ителә.

Ведомство норматив хокукый актларын, шул исәптән «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү

хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән гаризалар һәм белдерүләр формаларын раслаучы, күрсәтелгән гаризаларга һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучыларның төбәк реестрыннан, җиңел такси заказ хезмәтләренең төбәк реестрыннан өземтәләргә карата карарлар кабул итү турында белдерүләр һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар тарифлар турында мәгълүмат урнаштырсын өчен сайтны билгеләүне күздә тотучы актлар чыгару таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.